# Бәйләгеч сүз төркемнәре

- Бәйлек.
- Бәйлек сүзләр.

***Җөмләдәге сүзләргә сораулар куеп, нинди сүз төркеме икәнен әйтегез. Кайсы сүзләргә сорау куеп булмый?***

*** Абагаларны күрмәс өчен, Рөстәм аларга арты белән борылды.** ***(Г.Кутуй)***

*** Сара таулардагы агачлыкка кадәр барып җиткән.**

** Сорау куеп булмаган сүзләр җөмләләрдә ни өчен кирәк?*
** Алар нинди сүз яки җөмләләрне бәйлиләр?*

**Кагыйдә.**

**Бәйлек, ияртүче кисәк белән ияртүче кисәк, иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасындагы төрле бәйләнешләрне белдереп, аларны үзара бәйләү хезмәтен үти.**

****Бәйлекләр нинди сүз төркеменә керә?***

# Сүз төркемнәре.

## Мөстәкыйль сүз төркемнәре

*-исем, сыйфат, сан,*
*-алм-к, фигыль,*
*-рәвеш, аваз иярт.,*
*-хәбәрлек сүзләр.*

## Бәйләгеч сүз төркемнәре

*-бәйлек (бәйлек сүзләр),*
*-теркәгеч (теркәгеч сүзләр)*

## Модальлек сүз төркемнәре

*-Кисәкчә,*
*-Ымлык.*

*** Бу җөмләдә бәйләгеч сүз төркемнәрен әйтегез?**

**Тугай уртасында түгәрәк күл,-**

**Түм-түгәрәк тулган ай кебек.** ***(Ф.Кәрим)***

*** Уртасында** ***сүзе нинди сүз төркеме?***

***( Бәйлек хезмәтен үти торган мөстәкыйль сүз төркеме –*** **бәйлек сүз*****)***

- ***Теркәгеч.***
- ***Теркәгеч сүзләр***

- **Кенәри читлектә утыра <u>һәм</u> бертуктаусыз сайрый.**
- **Рөстәм озак көтте, <u>ләкин</u> абага чәчәк атмады.** ***(Г.Кутуй)***

* ***<u>Һәм, ләкин</u> сүзләре кайсы сүз төркеменә карыйлар?***

* ***Алар бәйлекме (предлог)?***

***( Теркәгеч – союз)***

# Кагыйдә.

Җөмлә кисәкләрен һәм кушма җөмләдә гади җөмләләрне бәйли торган бәйләгеч сүз төркемнәре **ТЕРКӘГЕЧ** дип атала.

**Теркәгечләрне табып, аларның нинди максат белән кулланылганын аңлатыгыз.**

***Казан – борынгы һәм тарихи шәһәр. Мең ел эчендә ул күп вакыйгалар кичергән, ләкин данлы исемен югалтмаган. Башкалабыз Сөембикә манарасы яки Кол Шәриф мәчете белән генә дә горурлана ала. Казан минем өчен кадерле, чөнки биредә туганмын, тәүге адымнарымны атлаганмын.***

# Теркәгечләр.

- **Тезүче**

1.**Җыючы:** *янә, вә һәм (да,дә;та,тә), тагы(н),*

2.**Бүлүче:** *я, яки, яисә*

3.**Каршы куючы:** *ләкин, әмма, тик, фәкать, бәлки, ә*

- **Иярт үче**


*(чөнки, гүя, ки, гүяки, әгәр, гәрчә)*

***Экранда күрсәтелгән Казан күренешләре рәсемнәреннән файдаланып, теркәгечләр кулланып* “Казаным” *темасына хикәя төзегез.***

***Терәк сүзләр*: Сөембикә манарасы,**

**Кол Шәриф мәчете, борынгы, горурлана, меңъеллык Казан һ.б.**





Сөембикә манарасы



